**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**«Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең аерым территорияләрендә хайваннар котыру авырулы булганга, аларның имин булмавы сәбәпле кертелгән чикләү чараларын (карантинны) бетерү турында**

Котыру чиренә бирешүчән соңгы авыру хайванның үләксәсе юкка чыгарылган көннән 60 календарь көн узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының 3[1] статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Лекарево авыл җирлеге Лекарево авылындагы Комаровка урамы 8 нче йортта урнашкан шәхси йорт хуҗалыгы территориясендә һәм «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Лекарево һәм Танай авыл җирлекләрендә урнашкан, эпизоотия чыганагы чикләреннән 2 км радиустагы территориядә хайваннар котыру авырулы булганга, аларның имин булмавы сәбәпле кертелгән чикләү чараларын (карантинны) бетерергә.

2. Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең аерым территорияләрендә хайваннар котыру авырулы булганга, аларның имин булмавы сәбәпле чикләү чаралары (карантин) кертү турында» 2025 елның 2 сентябрендәге 700 номерлы Указы үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ • АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2025 ел, 08 ноябрь
№ 923